# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫНДА ХХ ЙӨЗ БАШЫ ШИГЪРИЯТЕ

Татар әдәбияты тарихында ХХ йөз башы нинди урын тота? Бу – бик колачлы сорау. Аңа җавап биргәндә, әдәбиятыбыз тарихының борынгы һәм урта гасыр дәверен, XIX йөзне күздән кичерергә һәм татар әдәбиятының гасырыбыз дәвамындагы үсешен күздә тотарга тиешбез.

ХХ йөз башында татар әдәбияты гигант сикереш ясый. Үсеш инерциясе, алгарыш куәсе узгандагы озын гомерле һәм бай мираска таянмаганда, бу – мөмкин булмаган эш. Ходайга шөкер, безнең андый мирасыбыз бар. Болгар дәүләт дәвере дә, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорлары да безгә бөек мәгънәви мирас калдырган. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы да, Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е дә, Хәрәзми һәм Хөсам Кятиб поэмалары да, Сәйф Сараи «Гөлстан»ы да, Мәхмүд бине Гали чәчмәсе дә, Мөхәммәдьяр һәм Кол Шәриф шигърияте дә – халкыбызга һәрвакыт үзенең бөеклеген тоеп яшәргә нигез биргән бәрәкәтле байлык. Шушы мәгънәви мая татар халкына, дәүләтсез калып, бәйсезлеген югалткач та, бөтенләй гаҗизлеккә төшмәскә, яшәүгә һәм җиңүгә ихтыярын җуймаска ярдәм иткән. Бары шушы ихтыяр һәм тыелгысыз тернәкләнү инерциясе генә XIX йөздә

элекке биеклекләрне кайтарырга, Габдерәхим Утыз Имәни, Габделҗәббар Кандалый, Әбелмәних Каргалый, Шәмсетдин Зәки, Гали Чокрый, Акмулла кебек гүзәл шагыйрьләр һәм олуг фикер ияләре йолдызлыгын кабызырга мөмкинлек биргән. Бары шушы алшартлар нигезендә генә XX йөз башы татар әдәбияты кебек балкулы феномен дөньяга килә алган.

Дөрес, болар артында мәгълүм иҗтимагый шартлар, сәяси-икътисади тормыштагы зур җанланыш ята. XIX гасыр дисәк, феодаль торгынлыкны кузгатып, капиталистик мөнәсәбәтләр урнашу һәм татар халкының милләт буларак формалашуын истә тотарга тиешбез. Ә инде XX йөз башында Русиянең икътисади, иҗтимагый-сәяси тормышындагы зур үзгәрешләр, беренче Русия инкыйлабы милли уянышка этәргеч бирә, татар халкына күз карашын Аурупадагы алдынгы илләр, милләтләр тормышына юнәлтергә һәм үзе өчен җитди гыйбрәтләр алырга сәбәпче була. Шул чор кичерешләре, милләтнең җанын тарихи перспективасызлыктан коткару нияте тикмәгә генә кискен һәм хәтәр рәвештә Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән кисәтүчән публицистикасын китереп чыгармаган бит! Милли уяныш, дөресрәге, милли яңарыш идеологы үзенең халкын, шул рәвешле, гайрәтле гамәлгә, мәгърифәткә, аурупачыл иҗтиһатка чакырган.

Ә шулай да узгандагы әдәби мираска, сүз сәнгате үсешенә XX йөз башы әдәбиятының мөнәсәбәте нинди? Гасыр башындагы үсеш, күтәрелеш инерциясен, һичшиксез, шушы мирас тәэмин итә. Әмма әле без күзәтә торган чор ул мирасны ничек күтә-

реп ала яки дәвам итә? Әллә нәрсәнедер кире дә кагамы?

XX йөз башы татар әдәбияты күп гасырлык үсешкә йомгак ясый, аның барлык мөһим үзенчәлекләрен бергә төйни һәм яңа шартлар нигезендә трансформацияли. **Бу башлыча шигърият казанышларында күзәтелә.** Без алдарак урта гасыр әдәби ядкярләрен санап чыктык. Ә төрки әдәби традицияләр, шигъри стилистика үсеше аннан да элекке дәверләр казанышына, Орхон-Енисей язмаларына, хәтта тагын да борынгырак һун дәверенә барып тоташа. XX йөз башы шигърияте шуларның барын да үзенең сәнгатьчәлек хәзинәсенә ала. Бу Тукайда, Дәрдемәндтә һәм алар мәктәбенә тартылган күп санлы башка шагыйрьләрдә күзәтелә.

XX йөз башы татар тормышында көч алган омтылышларга күз салсак, ашкынып аурупалашуны күрербез. Бу – мәгърифәтчеләр эшчәнлеге нәтиҗәсе, бу – гомумрусия иҗтимагый хәрәкәтләре йогынтысы, бу – татар зыялыларының Париж, Истанбул вә башка Аурупа үзәкләрендә белем алу нәтиҗәсе, бу – рус уку йортлары, рус матбугаты белән танышып бару, бәйләнештә булу нәтиҗәсе. Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан әсәрләрендәге үзәк мотивларның берсе дә шул.

Тукай шигырьләренең кайберләренә куелган җәя эче искәрмәләренә күз салсак, «Шекспирдән», «Гетедән», «Толстой сүзләре», «Толстой фикере» яки «Пушкиннән», «Лермонтовтан» дигән сүзләрне укырбыз. Шигъри мотивларны исә Һенрих Һәйне, Байрон исемнәренә бәйләү очрый. Сәгыйть Рәмиев Шиллернең

романтик сюжетларын ала. Сәгыйть Сүнчәләй Һәйненең «Әлмансур»ын тәрҗемә итә. Дәрдемәнд китапханәсендә Гөте, Һәйне әсәрләре булган. Ул Пушкинны, Фетне, Тютчевне яраткан һәм тәрҗемә иткән. Бу нәрсә дигән сүз? Татар шигыре үзенең гасырга хас йөзен барлыкка китерә, ике бөек шигъри дөнья – Шәрекъ һәм Көнбатыш традицияләрен үзендә туплый, бергә үрә һәм шигъри үрелешнең уникаль үрнәкләрен бирә дигән сүз; Дәрдемәнднең табигать лирикасында Гөтене хәтерләткән галәми колач, табигать авазлары белән кушылып киткән тирән уйланулар, кичерешләрнең катлаулы үрелеше бер дә юктан барлыкка килмәгән бит. Әгәр бу шагыйрьне күздә тотсак, табигать тасвирен хасил иткән төсләр үрелешендә XX йөз башы Аурупа, хосусан француз шигъриятендә барган сәнгати эзләнүләрнең кайтавазын да, импрессионистик-сюрреалистик төсмерләрне дә абайлап була. Болар аның шушы шигырендә аеруча тоемлана:

Сеңеп җиргә, менеп җилгә, булып бу,
Агып кичмәктәдер гөрләп агымсу.

Агач, ташлар тынып, таулар да тыңлар,
Менеп таштан, очып ташка, төшеп су.

Ага гөрләп, ага зарлап агымсу,
Китә йомгакланып-йомгакланып бу.

Качан, балкып, җиһанга тулды якты,
Килеп, нур агълаган тауларны бакты, –

Дәрийгъ, нур күз яшен бәллүр санды,
Кереп әлванга, ал канга буянды.

Ишет төннәрдәге былбыл фиганен,
Аның да бакчы, залим, якты җанын.

Очып, чүлләр кичеп, таулар ашып
Килеп төшкән микән, башкай адашып?

Ят илнең яд итеп якты кояшын,
Камышлы суларын, кырчынлы ташын,

Тавышлар чыңрауын ул саф һавада,
Сагышлар яңратып иркен далада.

Ерак диңгездә ул кышлар кичергән,
Чит илләрдән гариб моңлар китергән.

Сезанн, Моне, Ренуар, Модильяни киндерләрендәге төсләр, табигатьтәге үзгәреш-күренешләрдә кеше җанына хас хәрәкәтләр күрү, былбыл язмышына бәйле мотивларда чагылган инсанчы җаны бу әсәрне XX йөз башы шигъриятенең мөһим ачышлары рәтенә куя. Моңа охшаш әсәрләр татар әдәбиятындагы Көнчыгыш-Көнбатыш синтезының мөһим гәүдәләнеше булып торалар, һәм бу синтез – безнең әдәбияттагы тизләтелгән үсеш факторы да.

Татар әдипләренең Аурупа әдәбияты белән шулай якыннан һәм тирән танышуына нинди шартлар ярдәм иткән соң?

Югарыда әйтеп узганча, татар зыялыларының Көнбатыш Аурупа уку йортларында белем алуы да, аеруча рус телен, рус әдәбиятын белүләре дә ярдәм иткән. Күбесенчә диярлек әдипләр Көнбатыш авторларын русча тәрҗемәдә укыган. Әмма алай гына түгел. Без татар әдәбиятының төрек әдәбияты белән тыгыз бәйләнештә үскәнлеген истән чыгармаска ти-